ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 май 2026 ел №4985

Башкарма комитетның 2026 елның 20 гыйнварындагы 303 номерлы Карары белән расланган территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясындагы 16 пунктның 1 пунктчасы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2026 елның 20 гыйнварындагы 303 номерлы Карары белән расланган территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 16 пунктына, 1 пунктчаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1) җир участогының урнашу схемасы аның формасына, форматына яки аны әзерләүгә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 статьясындагы 12 пункт нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов